| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кучуковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Көчек авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2020 Түбән Көчек авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Көчек торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башлыгы к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 27 ноябрендә 09 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2020 елның 27 ноябрендә 11 сәг 00 мин билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 3 этабын 2020 елның 27 ноябрендә 14 сәг 00 мин билгеләргә.

4. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Түбән Көчек авылының К. Маркс, Тукай урамнарында яшәүчеләр.

-2 этап: Түбән Көчек авылының Ленин, Колхоз, Яңа урамнарында яшәүчеләр.

-3 этап: Түбән Көчек авылының Казан, Калинин урамнарында яшәүчеләр.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп раслаpга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Көчек торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Бишенче линия урнаштыру, Түбән Көчек авылында лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны ремонтлау һәм яктырту өчен материаллар сатып алу;

2. Түбән Көчек авылының К. Маркс урамы, Ленин урамы, Колхоз тыкрыгы, Тукай тыкрыгы юлларына вак таш сатып алу һәм җәю;

3. Юлларга хезмәт күрсәтү-Түбән Көчек авылын кардан чистарту;

4. Түбән Көчек авылының Яңа һәм Ленин урамнары буенча материаллар сатып алу һәм су челтәрләрен алыштыру;

5. Түбән Көчек авылында янгын сүндерү машинасын карап тоту, ремонтлау, штаттан тыш хезмәткәрләргә хезмәт килешүе буенча түләү);

6. Түбән Көчек авылында су башнясын койма белән әйләндереп алу һәм материаллар сатып алу;

7.Түбән Көчек авылында күмү урыннарын карап тоту (зират коймасын яңарту);

8. Түбән Көчек авылы өчен Бөек Ватан сугышы һәйкәлен сатып алу һәм урнаштыру;

9. Түбән Көчек авылында кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган үсентеләрне кистерү;

10.МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылмалы җиһазлар сатып алу (төягеч һәм ротор чапкыч).

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Түбән Көчек авылы, Ленин ур. 12 адресы буенча урнашкан авыл клубында уздырырга.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.А.НУРМӨХӘММӘТОВ